| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 05 2022 ел № 187

«Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясен төзү турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында» 2001 елның 15 апрелендәге 251 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Югары белем бирү мәгариф оешмаларында максатчан юнәлеш буенча укырга дәгъвачылар исемлегенә кертү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясен турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1. пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү мәгариф оешмаларына максатчан кабул итүне оештыру һәм уздыру тәртибе буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 886 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов